

Гадәт  буенча, ел саен Темников районы Аксель авылында “За-Валенки” кышкы регионара фестиваль уза, быел да үтте. Татарларыбыз да бу чарада теләп  катнаша. Мәсәлән, Митрял белән Тархан авылы (СК “Тархановский”)  “Татарское подворье” оештырып алып барганнар.

Фестивальгә традицион рәвештә киез итек житештерүчеләр килә. Беренче ел  гына үз продукциясен Атюрьево районыннан Сергей Рапин тәкъдим итми. Аны  әтисе ойрәткән. Сәүдә белән канәгать. Фестивальдә катнашу кысаларында  оста аяк киемен сату белән генә чикләнми, ә аны ничек ясавын да күрсәтә.
Чесанка, катанка, киез итек, пима Россиянен торле почмакларында  табигый сарык йонынннан ясалган кышкы аяк киеме аталмалары. Жылы, унайлы,  алар салкында аякларын да, жанын да жылыталар. Кыска һәм озын, соры һәм  ак, кошлар һәм жиләкләр белән ясалган киез итекләр кайнар пироглар  кебек очып киткәннәр.



-  Ойдә кияргә дип безнен Темник ягы татарларыбыз кыска оек - катый  (чүни-пиманы) сайлыйлар. Резинка калуш киертеп чесанкасы да йорт  хайваннары арасында кияргә шәп. Акселга аяк киеме сатып алырга күрше  районнардан, шулай ук Саров һәм Саранск халкы да ел саен килә, быел да  килгәннәр. Ойдә кияргә ясалган жылы аяк киеме, чуни дип аталганы, зур  ихтыяж белән сатылды бу конне. Күпләр модалы киез итекне киеп йори кыш  коне, - ди фестивальдә катнашучы Тархан авылы клубы житәкчесе, хормәтле Нурия Шарифжан кызы Муратова.
Традиция буенча бу конне валенкаларга  чын бәйрәм оештырыла: авыл уртасындагы элеккеге базар мәйданында музыка  янгырый, конкурслар узды. Үзешчән сәнгать коллективлары халыкны үз  чыгышлары белән шатландырды. Гастрономия күргәзмәсендә районнын авыл  жирлекләре вәкилләре катнашты. Тархан бәлешләрен яратып сатып алдылар.  Фестивальдән кунак-лар декоратив-кулланма сәнгать товарларын алып  китәләр. Фотозона да эшләгән. Балаларны мәктәптән тыш эш үзәге активистлары уеннар уйнат-кан. Коч, тизлек, житезлек күрсәтеп, спорт  мәйданчыгы аерылып торган. Тамашачыларны “Беренчеләр хәрәкәте” ннән  волонтерлар һәм актив яшьләр күнел ачкан. Барысы да халык очен  оештырылган. Ин күнеллесе – хәзер яшьләр дә киез итек - валенки кия,  модада диләр.

**Наилә НАСЫРОВА**